**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_24_» ___02____ 2025 ел.** **№ __44___**

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, Башкарма комитетның 2025 елның 24 февралендәге 42 номерлы «2025 елга Азнакай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында»гы карары нигезендә,

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

1.1.1 Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 1186 362 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 2 372 724 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 3 559 086 сум;
1.1.4 Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 4 745 448 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 5 931 810 сум;
1.1.6 Алты кешедән торан гаилә өчен - 7 118 172 сум;
1.1.7 Җиде кешедән торган гаилә өчен - 8 304 534 сум;
1.1.8 Сигез кешедән торган гаилә өчен - 9 490 896 сум;

1.1.9 Тугыз кешедән торган гаилә өчен - 10 677 258 сум;

1.1.10 Ун  кешедән торган гаилә өчен – 11 863 620 сум;

1.2 Гражданин гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме 57 041 сум 24 тиен тәшкил итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче                                                            А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына №1 кушымта
«____» _________2025 № _____

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы**

1. Наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ= НП х РС РЦ, биредә

СЖ - исәп күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урынны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында»гы 2025 елның 30 гыйнварындагы 34 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НП хаты нигезендә Азнакай муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе 65 909 сум тәшкил итә.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,25 х РС), биредә

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп күрсәткече;

ПС - кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма), ипотека торак кредитлавы буенча ставка - елына 21%, ягъни аена 21%/100/12=0,017).

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны 292,1 ай тәшкил иткән.

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

Айлык уртача җыелма керемнең максималь әһәмиятен билгеләү

| РС гаиләсе әгъзалары саны | Торак урын бирү нормасы буенча базар бәясенең исәп күрсәткече (СЖ) | Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (уртача еллык - 21%) ПС (21/100/12) | 0,7*СЖ*ПС | 1-(1+ПС)$^{-}$ $^{292,1}$) | 0,25*РС | 1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме: |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1186362 | 0,017 | 14117,7078 | 0,99 | 0,25 | 57041,24 |
| 2 | 2372724 | 0,017 | 28235,4156 | 0,99 | 0,5 | 57041,24 |
| 3 | 3559086 | 0,017 | 42353,1234 | 0,99 | 0,75 | 57041,24 |
| 4 | 4745448 | 0,017 | 56470,8312 | 0,99 | 1 | 57041,24 |
| 5 | 5931810 | 0,017 | 70588,539 | 0,99 | 1,25 | 57041,24 |
| 6 | 7118172 | 0,017 | 84706,2468 | 0,99 | 1,5 | 57041,24 |
| 7 | 8304534 | 0,017 | 98823,9546 | 0,99 | 1,75 | 57041,24 |
| 8 | 9490896 | 0,017 | 112941,662 | 0,99 | 2 | 57041,24 |
| 9 | 10677258 | 0,017 | 127059,37 | 0,99 | 2,25 | 57041,24 |
| 10 | 11863620 | 0,017 | 141177,078 | 0,99 | 2,5 | 57041,24 |

Милекнең базар хакының исәп-хисап күрсәткечен билгеләү

| Гаилә әгъзаларының саны | Торак бирү нормасы | Гомуми мәйданы | Уртача 1 кв.м базар бәясе | Базар бәясенең исәп күрсәткече (СЖ) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 18 | 18 | 65 909 | 1186362 |
| 2 | 18 | 36 | 65 909 | 2372724 |
| 3 | 18 | 54 | 65 909 | 3559086 |
| 4 | 18 | 72 | 65 909 | 4745448 |
| 5 | 18 | 90 | 65 909 | 5931810 |
| 6 | 18 | 108 | 65 909 | 7118172 |
| 7 | 18 | 126 | 65 909 | 8304534 |
| 8 | 18 | 144 | 65 909 | 9490896 |
| 9 | 18 | 162 | 65 909 | 10677258 |
| 10 | 18 | 180 | 65 909 | 11863620 |